СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2021 г. Заинск № 75

**2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре бюджеты турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

## КАРАР ИТТЕ:

**Статья 1**

1. 2022 елга Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 154853,6 мең сум итеп;

2) Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 154853,6 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджеты кытлыгын 0 күләмендә.

2. 2023 елга һәм 2024 елга Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2023 елга – 160737,8 мең сум һәм 2024 елга 167978,5 мең сум күләмендә;

2) Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2023 елга 160737,8 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 4179,8 мең сум һәм 2024 елга 167978,5 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнарны 8566,9 мең сум күләмендә;

3) Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджеты кытлыгы 2023 елга 0 мең сум һәм 2024 елга 0 мең сум күләмендә.

3. 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль

районы Зәй шәһәре бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

1. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең 2023 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең 2024 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең 2025 елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының югары чиген 0 мең сум, шул исәптән Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычының югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга.

**3 статья**

Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджетында 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

1. 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар план чорына Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2022 елга, 2023 - 2024 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 кушымта нигезендә расларга.

3. Зәй муниципаль районы бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2022 елга 0 мең сум, 2023 елга 0 мең сум, 2024 елга 0 мең сум итеп расларга.

**5 статья**

1. Вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру буенча төзелгән килешүләр нигезендә Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджетыннан Зәй муниципаль районы бюджетына җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен түбәндәгеләргә расларга:

- күпфатирлы торак йортларга капиталь ремонт ясауга 2022 елда 15984,0 мең сум, 2023 елга 15984,0 мең сум, 2024 елга 15984,0 мең сум итеп;
- Зәй муниципаль районы Зәй шәһәрендә яшәүчеләрне мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү буенча 2022 елга 65670,4 мең сум, 2023 елга 70589,6 мең сум, 2024 елга 76714,7 мең сум күләмендә;

2. 2022-2024 елларда әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджетыннан Зәй

муниципаль районы бюджетына күчерү ай саен, тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

**6 статья**

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләр бюджетларына дотацияләр күләмен Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджетында 2022 елга 3110,6 мең сум, 2023 елга 2305,8 мең сум, 2024 елга 2387,7 мең сум итеп расларга.

**7 статья**

Юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затлар - товар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә бирелә.

**8 статья**

Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнарына 2022 елда Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль хезмәткәрләре, шулай ук Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре һәм Зәй муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә.

**9 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы казначылык департаментының Зәй районы буенча территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

**10 статья**

Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар нигезендә 2021 елда түләнергә тиешле товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджетының 2022 елның 1 гыйнварына булган калдыклары 2022 елда Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**11 статья**

Әлеге карарны «Новый Зай», «Зәй офыклары» газеталарында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

**12 статья**

Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Совет Рәисе** **Р.Г.Кәримов**